ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.07.2019 1154

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының ярдәм итү һәм үсеш фонды» муниципаль автоном учреждениесен бетерү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 423600, Татарстан Республикасы, Алабуга районы, Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 44 нче йорт адресы буенча урнашкан: «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының ярдәм итү һәм үсеш фонды» муниципаль автоном учреждениесен (ТДТН /төп дәүләт теркәү номеры/ 1051655067738, СТИН /салым түләүченең идентификация номеры/ 1646017900) бетерергә.

2. 2005 нче елның 10 нчы ноябрендәге «Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә ярдәм итү фонды» МУ булдыру турында»гы 1054 нче номерлы карарны гамәлдән чыгарырга.

3. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының ярдәм итү һәм үсеш фонды» муниципаль автоном учреждениесен ликвидацияләү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).

4. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып дүрт айдан да соңга калмыйча «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының ярдәм итү һәм аны үстерү фонды» МАУ бетерү процедурасын гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карар аңа кул куйган көннән һәм халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче в.б. Л.Ф. Нургаянов

1 нче кушымта
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
24. 07. 2019 , 1154 нче
санлы карары белән расланган

**«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының ярдәм итү һәм үсеш фонды» муниципаль автоном учреждениесен ликвидацияләү комиссиясе ссоставы**

**<u>Комиссия рәисе:</u>**

| | | |
|---|---|---|
| Нургаянов Л.Ф. | - | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының җитәкче вазыйфасын башкаручы |

**<u>Комиссия әгъзалары</u>**

| | | |
|---|---|---|
| Драгун Т.В. | - | «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының ярдәм итү һәм үсеш фонды» муниципаль автоном учреждениесе директоры |
| Петров Е.Ю. | - | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Җир-мөлкәт палатасы рәисе |
| Бусыгина О.Г. | - | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Хокук палатасы рәисе |
| Билалова Г.С. | - | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Җир-мөлкәт палатасы рәисе урынбасары |